КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 декабрь г.Казань № 1095

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 февраль, 66 нчы; 2015 ел, 12 сентябрь, 670 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1101 нче; 2019 ел, 15 май, 393 нче; 2020 ел, 17 август, 688 нче; 2022 ел, 7 июнь, 535 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«муниципаль комиссия рәисе итеп муниципаль район, шәһәр округы башлыгы (шәһәр эчендәге муниципаль комиссиядә – шәһәр округындагы җирле администрациясенең территориаль органы җитәкчесе) билгеләнә;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин